| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.03.2013 № 10-5/кс

Казан ш.

***«Российские железные дороги» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогы өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тарифлар билгеләү турында***

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә тарифларны, өстәмәләрне һәм чикле индекслы бәяләр билгеләү һәм җайга салу нигезләре турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карар бирә:

1. Әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Российские железные дороги» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга әлеге карар кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2013 елның 01 апреленнән 2014 елның 31 мартына кадәр гамәлдә була.

3. Кайнар су белән тәэмин итүче «Российские железные дороги» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогының җитештерү программасының төп күрсәткечләрен әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә килештерергә.

4. Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «Российские железные дороги» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогына ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә,

чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Әлеге карар белән билгеләнгән кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системаларында кайнар суга тарифлар Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2012 елның 27 февралендәге 45 номерлы «Коммуналь комплекс оешмалары товарларын һәм хезмәтләрен кулланучылар өчен һәркем файдалана алырлык критерийлар системасын билгеләү турында» боерыгы белән расланган коммуналь комплекс оешмаларыннан кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге критерийларына туры килә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
01.03.2013 № 10-5/кс
карарына кушымта № 1

# «Российские железные дороги» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогы өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тарифлар (календарь буенча бүленгән)

| № п/п | Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (бер компонентлы) | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м. | | Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал | |
| | | 2013 елның 01 апреленнән 2013 елның 30 июненә кадәр | 2013 елның 01 июленнән 2014 елның 31 мартына кадәр | 2013 елның 01 апреленнән 2013 елның 30 июненә кадәр | 2013 елның 01 июленнән 2014 елның 31 мартына кадәр |
| 1 | «Российские железные дороги» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогы | | | | |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге кулланучылары, шул исәптән: | | | | |
| | Торак секторында кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымы белән күрсәтелә)* | 15,87 | 16,26 | 1085,73 | 1184,19 |
| | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 13,45 | 13,78 | 920,11 | 1003,55 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының (икенче өлеш) 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм

теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.03.2013 № 10-5/кс карарына кушымта № 2

## Кайнар су белән тәэмин итүче «Российские железные дороги» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогының җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| № п/п | Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы оешманың җитештерү программасы күрсәткечләре, мең куб метр. | | | | | | Планлы тулай табыш, мең сум (өстәмә хак салымыннан башка) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Челтәргә бирелгән су | Җибәрелгән су, шул исәптән: | | | | | |
| | | | Барлыгы | Предприятие ихтыяҗлары өчен су чыгымы | Халык | Бюджет куллану чылары | Башка төр куллан учылар | |
| 1 | «Российские железные дороги» ААҖ филиалы – Җылылык һәм су белән тәэмин итү буенча үзәк дирекциянең структур бүлекчәсе – Горький дирекциясенең Казан территориаль участогы | 20,647 | 20,647 | 0,0 | 18,447 | 0,0 | 2,2 | 1570,46 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм